ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

Х. Такташа ул., 94, а/я 44, Казань, 420107

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ, ӘЙЛӘНЕШЕ
ҺӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ
КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН
ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь
инспекциясе)

Һ.Такташ урамы, 94 нче йорт, Казан шәһәре, 420107

# БОЕРЫК

19.04.2018 № 12-07/60

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь
инспекциясенең ведомство бүләкләре турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, “Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле инспекция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенең (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе) дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең эшкә карата кызыксындыруын көчәйтү һәм тел-теш тидергесез эшләү һәм нәтиҗәле дәүләт хезмәте өчен бүләкләү, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе хезмәткәрләрен һәм ведомство карамагындагы хезмәткәрләрне хезмәт эшчәнлегендә югары нәтиҗәләргә ирешкән өчен бүләкләү системасын камилләштерү максатыннан чыгып, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең ведомство бүләкләрен гамәлгә куярга:

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең мактаулы хезмәткәре” медален;

“Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медален;

“Булышлык күрсәткән өчен” медален;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Мактау грамотасын;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең Рәхмәтен.

2. Расларга (кушымта итеп бирелә):

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибен;

“Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең мактаулы хезмәткәре” медале турында нигезләмәне;

“Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медале турында нигезләмәне;

“Булышлык күрсәткән өчен” медале турында нигезләмәне;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Мактау грамотасы турында нигезләмәне;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең Рәхмәте турында нигезләмәне.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлегенә (Эйдинов Б.Г.) бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлегенә (Василина Л.П.) бу боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе структур подразделениеләре һәм территориаль органнары җитәкчеләре игътибарына җиткерергә.

5. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **Җ.Й.Әхмәтханов**

Кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы
көрәш бүлеге начальнигы _____________________________/Л.П. Василина/____________

Административ һәм суд практикасы
бүлеге
начальнигы урынбасары ________________________________/И.И. Җамалетдинов/_________

Татарстан Республикасы
Дәүләт алкоголь
инспекциясенең
19.04 2018 ел,

№12-07/60 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең ведомство бүләкләре белән бүләкләү**
**ТӘРТИБЕ**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең ведомство бүләкләре (алга таба – ведомство бүләкләре) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы белән килештерелгәннән соң Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы нигезендә гамәлгә куела.

2. Ведомство бүләкләрен саклау, учетын алып бару һәм тапшыру һәм ведомство бүләкләре белән бүләкләүгә материаллар рәсмиләштерү, шулай ук бүләкләнгән хезмәткәрләрнең учетын алып бару эшен оештыруны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коорупциягә каршы көрәш бүлеге хәл итә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм “Республика бәйсез экспертиза һәм куллану базарына мониторинг үзәге” дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – «Татэкспертцентр» ГБУ) хезмәткәрләрен ведомство бүләкләре белән бүләкләү (алга таба – бүләкләү), статуслары нигезендә, түбәндәгеләр өчен хәл ителә:

хезмәт бурычларын үтәүгә карата намуслы мөнәсәбәт өчен;

Татарстан Республикасының этил спирты, алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итүгә һәм куллану базарында закон бозуларны кисәтүгә үзләреннән саллы өлеш керткән өчен;

хезмәткәрләрнең һәм ведомстволарның һөнәри бәйрәмнәрен, истәлекле һәм юбтлей даталарын билгеләп үткәндә, хезмәткәрләрнең юбилей даталарына (50 яшь, 55 яшь– хатын-кызлар өчен, 60 яшь һәм шуннан соң һәм һәр 10 ел узган саен).

3.1. Гражданнарны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең ведомство бүләкләре белән бүләкләү Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә һәм «Татэкспертцентр» ГБУга йөкләнгән бурычларны хәл кылуга җитди ярдәм күрсәткән өчен хәл ителә.

4. Ведомство бүләкләре белән бүләкләү турында карар, билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән үтенечнамә (Тәртипкә кушымта) нигезендә, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе тарафыннан кабул ителә, үтенечнамәдә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе аппараты һәм территориаль органнарының дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең, шулай ук «Татэкспертцентр» ГБУ хезмәткәрләренең һәм гражданнарның конкрет уңышлары, казанышлары һәм нәтиҗәләре күрсәтелә.

үтенечнамә компьютерда бастырып тапшырыла, анда сызу-бозулар, төзәтүләр булмаска тиеш.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе аппараты, территориаль органнар хезмәткәрләрен һәм гражданнарны бүләкләү турында үтенечнамә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең структур подразделениесе начальнигы тарафыннан тәкъдим ителә һәм имзалана.

Татаэкспертцентр» ГБУ хезмәткәрләрен бүләкләү турында үтенечнамә «Татаэкспертцентр» ГБУ җитәкчесе тарафыннан тәкъдим ителә һәм имзалана.

Бүләкләү турында үтенечнамә тапшырган вазыйфаи затлар үтенечнамәдә бәян ителгән мәгълүматларның дөреслеге һәм төгәллеге өчен җавап бирә.

5. Хезмәткәрне Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең ведомство бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим итү турында үтенечнамә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә яки «Татэкспертцентр» ГБУда кимендә 1 ел эшләгән хезмәткәргә карата язып тапшырыла:

6. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе аппараты, территориаль органнар хезмәткәрләрен, «Татэкспертцентр» ГБУ хезмәткәрләрен ведоомство бүләкләре белән бүләкләү Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы нигезендә, махсус бланкта рәсмиләштерелеп, хәл ителә.

7. Ведомство бүләкләрен тапшыру, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе тарафыннан, тантаналы шартларда, кагыйдә буларак, бүләкләнүчеләрнең эш урыннарында хәл ителә.

Ведомство бүләген Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе кушуы буенча тапшырырга мөмкин:

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасарлары;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органнары начальниклары;

«Татэкспертцентр» ГБУ җитәкчесе.

8. Хезмәткәрләрне ведомство бүләкләре белән бүләкләү турында мәгълүматлар бүләкләнелгән затларның личное делосына һәм хезмәт кенәгәсенә кертелә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтына урнаштырыла.

9. Һөнәри бәйрәмнәргә, шулай ук хезмәткәрләрнең һәм ведомствоның истәлекле һәм юбилей даталарына багышланган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең ведомство бүләкләре белән бүләкләү турында үтенечнамә һөнәри бәйрәмгә, истәлекле яки юбилей датасына кимендә бер ай кала Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коорупциягә каршы көрәш бүлегенә тапшырыла.

10. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең ведомство бүләге югалтылган очракта, дубликаты бирелми.

Татарстан Республикасы
Дәүләт алкоголь
инспекциясенең ведомство
бүләкләре белән бүләкләү
тәртибенә

КУШЫМТА

Татарстан
Республикасы Дәүләт
алкоголь инспекциясе
җитәкчесе
Ж.Й.Әхмәтхановка

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең ведомство бүләге белән бүләкләү турында
**ҮТЕНЕЧНАМӘ**

Тәкъдим итәм ________________________________________________
(хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме)
________________________________________________________________

ведомство бүләге белән бүләкләүгә:
(бүләк атамасы)
________________________________________________________________
( казанышлары һәм эшчәнлеге күрсәткечләре турында кыскача гына характеристика)
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
____________________________________________________

Татарстан Республикасы
Дәүләт алкоголь инспекциясенең
(территориаль орган)
бүлек начальнигы
______________________
(фамилиясе, инициаллары, имзасы)

Татарстан Республикасы
Дәүләт алкоголь
инспекциясенең
19.04. 2018 ел,
№12-07/60 боерыгы белән

расланды

**“Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең мактаулы хезмәткәре” медале турында нигезләмә**

**1.** “Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең мактаулы хезмәткәре” медале Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең иң зур ведомство бүләге булып тора.

**2.** Медаль белән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыруга, норматив-хокукый җайга салуга үзләреннән саллы өлеш керткән, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә һәм “Татэкспертцентр” ГБУда кимендә 15 ел эшләгән, моңа кадәр “Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медале белән бүләкләнгән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең дәүләти гражданлык хезмәткәрләре һәм «Татэкспертцентр» хезмәткәрләре бүләкләнә.

Медаль белән, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе подразделениеләрендә яки «Татэкспертцентр» ГБУда кимендә 10 еллык эш стажы туплаган очракта, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә йөкләнгән бурычларны хәл кылуга үзләреннән зур өлеш керткән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең хезмәт ветераннары һәм пенсионерлар бүләкләнергә мөмкин.

**3.** Медальнең тасвирламасы һәм рәсеме бу Нигезләмәгә №1 кушымтада китерелгән. Медаьнең тасвирламасы һәм медальгә таныклык бланкы үрнәге бу Нигезләмәгә №2 кушымтада китерелгән.

**4.** Медаль күкрәкнең уң ягына тагыла.

“Мактаулы хезмәткәр” медале турында Нигезләмәгә №1 кушымта

**“Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең мактаулы хезмәткәре” медаленең тасвирламасы**

Медаль диаметры 38 мм лы ун почмаклы йолдыздан гыйбарәт: төрле зурлыктагы ике кырлы очлаеп торган нурлар бәйләменнән гыйбарәт булган биш нур төрле зурлыктагы, кырыйлары түгәрәкләнеп торган нурлар бәйләменнән гыйбарәт булган биш нур белән чиратлашып урнаштырылган. Йолдызның уртасында Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эмблемасы урнаштырылган. Аста, йолдыз өстендә, “ГОСАЛКОГОЛЬИНСПЕКЦИЯ” һәм “РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН” дип язып куелган аслы-өсле урнаштырылган алтынсу төстәге ике тасма җилферди.

Медальнең сул ягында уртада тәртип номеры урнаштырылган. Номер өстендә ярымтүгәрәк рәвешендә “Почетный сотрудник” дип, номер астында ярымтүгәрәк рәвешендә «Мактаулы хезмәткәр» дип язылган.

Медальдәге барлык сурәтләр һәм язулар да – рельефлы.

Медальнең уң һәм сул ягының тышкы контуры рантлар белән эшләнгән.

Медаль цинк эретмәсе белән корычтан эшләнеп, алтынсу төскә китерелә һәм йомшак эмаль белән каплана.

Калыбы корычтан эшләнә, алтынсу төскә кертелеп, йомшак эмаль белән каплана.

Медаль колак һәм божра ярдәмендә кызыл төстәге йомшак эмаль белән капланган, киңлеге 21 мм, биеклеге 16,5 мм га тигез булган дүрт почмаклы калыпка тоташтырыла.

Медальле калып эләктергеч ярдәмендә киемгә тагып куела.

Медальнең төсле макеты кушымта итеп бирелә.

Татарстан
Республикасы Дәүләт
алкоголь
инспекциясенең
мактаулы хезмәткәре”
медале турында
нигезләмәгә №2
кушымта

**“Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь**

**инспекциясенең  мактаулы хезмәткәре” медаленең төсле рәсеме**



“Мактаулы хезмәткәр” медале турында Нигезләмәгә №3 кушымта

**“Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең мактаулы хезмәткәре” медаленә таныклык бланкының тасвирламасы**

“Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең мактаулы хезмәткәре” медаленә таныклык бланкы ак төстәге калын катыргыдан эшләнә. Ачып куйгач, таныклык бланкы үлчәме – 140х100 мм.

Таныклык бланкының беренче битенә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эмблемасының график сурәте урнаштырылган. Аста түбәндәге язулар урнаштырылган: ИКЕ юлга – «ГОСАЛКОГОЛЬИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН», ике юлга – «УДОСТОВЕРЕНИЕ К МЕДАЛИ» һәм өч юлга – «ПОЧЕТНЫЙ СОТРУДНИК ГОСАЛКОГОЛЬИНСПЕКЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН». Эмблемасы сурәте һәм язулар кызыл буяу белән басылган.

Икенче битнең уртасында “Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең мактаулы хезмәткәре” медаленең төсле сурәте урын алган.

Өченче битнең югарыгы өлешендә – «УДОСТОВЕРЕНИЕ» дигән язу, язу астында – реквизитлар: фамилия, исеме, атасының исеме. Шуннан соң ике юлга – «Приказом Госалкогольинспекции Республики Татарстан» дигән сүзләр, түбәндәрәк бер юлга – «от» язуы һәм боерык реквизитлары: числосы, ае, елы һәм номеры урнаштырылган. Түбәндә бер юлга – «награжден(а) медалью» һәм өч юлга – «ПОЧЕТНЫЙ СОТРУДНИК ГОСАЛКОГОЛЬИНСПЕКЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» дигән сүзләр сыйдырылган. Шуннан соң ике юлда – «Руководитель Госалкогольинспекции Республики Татарстан» дигән сүзләр һәм мөхер урыны. «УДОСТОВЕРЕНИЕ» һәм «ПОЧЕТНЫЙ СОТРУДНИК» дигән сүзләр кызыл буяу белән, калган бөтен текст – кара буяу белән басылган.

Таныклык бланкы үрнәге

ГОСАЛКОГОЛЬИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

УДОСТОВЕРЕНИЕ
К МЕДАЛИ

«ПОЧЕТНЫЙ СОТРУДНИК
ГОСАЛКОГОЛЬИНСПЕКЦИИ РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН»

Таныклык бланкының эчке ягы үрнәге

| | |
|---|---|
| | Удостоверение<br>_______________________________________<br>фамилия<br>_______________________________________<br>имя<br>_______________________________________<br>отчество<br>_______________________________________<br><br>Приказом Госалкогольинспекции Республики Татарстан<br><br>от «_» ____20__г. №_____<br><br>награжден(а)<br>медалью<br>«ПОЧЕТНЫЙ СОТРУДНИК ГОСАЛКОГОЛЬИНСПЕКЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»<br><br>Руководитель Госалкогольинспекции Республики Татарстан<br>М.П. |

Татарстан
Республикасы Дәүләт
алкоголь инспекциясенең
_19.04. 2018 ел,
№12-07/60 боерыгы белән
расланды

**“Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медале турында**
**нигезләмә**

1. “Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медале Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең ведомство бүләге булып тора.

2. “Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медале белән, күпьеллык тел-теш тидергесез хезмәте, вазыйфаи бурычларын намус белән үтәве өчен, тиешле хезмәт стажына (Дәүләт алкоголь инспекциясендә һәм аның учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләп, моңа кадәр “Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Мактау грамотасы” белән бүләкләнгән) Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм «Татэкспертцентр» ГБУ хезмәткәрләре бүләкләнә.

3. Күпьеллык тел-теш тидергесез хезмәте, вазыйфаи бурычларын намус белән үтәве өчен Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм «Татэкспертцентр» ГБУ хезмәткәрләре “Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медале белән кабат бүләкләнергә мөмкин. Кабат бүләкләү алдагы бүләкләүдән соң кимендә 5 ел узгач хәл ителә.

3.1. Түбәндәге казанышлар өчен Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе күрсәтмәсе белән бүләкләүгә тәкъдим ителгәндә, “Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медале белән бүләкләү Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә һәм «Татэкспертцентр» ГБУда эш стажын, алдагы бүләкләнүдән соң 5 еллык срокны исәпкә алмыйча хәл ителә:

катлаулы һәм җаваплы бурычларны үтәүдәге зур уңышлар, аерым хезмәтләр күрсәткән өчен;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә һәм «Татэкспертцентр» ГБУга йөкләнгән бурычларны хәл кылудагы аерым хезмәтләр һәм шәхсән өлеш керткән өчен.

4. “Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медале күкрәкнең сул ягына, башка бүләкләр булганда, алардан сулдарак тагыла.

5. Медальнең тасвирламасы һәм рәсеме Нигезләмәгә №1 кушымтада киттерелгән. Медальгә таныклык бланкы тасвирламасы һәм үрнәге бу Нигезләмәгә №2 кушымтада китерелгән.

**“Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медаленең тасвирламасы**

Медаль диаметры  40 ммлы түгәрәк рәвешендә ясалган.

Медальнең уң ягына Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эмблемасы сурәтләнгән.

Эмблема “ Госалкогольинспекция Республики Татарстан” дип язылган тасма белән каймаланган.

Медальнең кире ягында, түгәрәкнең югары өлешендә – «За отличие в труде», түбәнге өлешендә – “Аерым хезмәт күрсәткән өчен” дигән сүзләр урнаштырылган.

Медальдәге барлык сурәтләр һәм язулар да – рельефлы.

Медальнең уң һәм сул ягының тышкы контуры рантлар белән эшләнгән.

Медаль цинк эретмәсе белән корычтан эшләнеп, алтынсу төскә китерелгән һәм йомшак эмаль белән капланган.

Медаль колак һәм бокра ярдәмендә яшел төстәге йомшак эмаль белән капланган, киңлеге 25,5 мм, биеклеге 18 мм га тигез булган дүрт почмаклы калыпка тоташтырылган.Тасма уртасында киңлеге 3,6 ммлы ак төстәге бер полоса бар.

Калыпның аскы өлешен калып уртасыннан уң һәм сул якка таба урнашкан башаклар үрелмәсе бизи.

Калып корычтан эшләнә, алтынсу төскә китерелеп, йомшак эмаль белән каплана.

Медальле калып эләктергеч ярдәмендә киемгә тагып куела.

Медальнең төсле макеты кушымта итеп бирелә.

“Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медале турында Нигезләмәгә №2 кушымта

**“Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медаленең төсле рәсеме**


Госалкогольинспекция Республики Татарстан


За отличие в труде
Аерым хезмәт күрсәткән өчен

“Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медале турында Нигезләмәгә №3 кушымта

**“Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медаленә таныклык бланкы тасвирламасы**

“Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медале медаленә таныклык бланкы ак төстәге калын катыргыдан эшләнә. Ачып куйгач, таныклык бланкы үлчәме – 140х100 мм.

Таныклык бланкының беренче битенә (ябып куелган рәвештә) Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эмблемасының график сурәте урнаштырылган. Эмблема астына түбәндәге язулар урнаштырылган: ИКЕ юлга – «ГОСАЛКОГОЛЬИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН», ике юлга – «УДОСТОВЕРЕНИЕ К МЕДАЛИ» һәм «ЗА ОТЛИЧИЕ В ТРУДЕ» дигән сүзләр.

Икенче битенең уртасына “Аерым хезмәт күрсәткән өчен” медаленең төсле сурәте урнаштырылган.

Өченче битнең югарыгы өлешендә – «УДОСТОВЕРЕНИЕ» дигән язу, язу астында – реквизитлар: фамилия, исеме, атасының исеме. Шуннан соң ике юлга – «Приказом Госалкогольинспекции Республики Татарстан» дигән сүзләр, түбәндәрәк бер юлга – «от» язуы һәм боерык реквизитлары: числосы, ае, елы һәм номеры урнаштырылган.

Түбәндә бер юлга – «награжден(а) медалью» һәм тагын бер юлга – «ЗА ОТЛИЧИЕ В ТРУДЕ» дигән сүзләр сыйдырылган. Шуннан соң ике юлда – «Руководитель Госалкогольинспекции Республики Татарстан» дигән сүзләр һәм мөһер урыны. «УДОСТОВЕРЕНИЕ» һәм «ЗА ОТЛИЧИЕ В ТРУДЕ» дигән сүзләр кызыл буяу белән, калган бөтен текст – кара буяу белән басылган.

Таныклык бланкы үрнәге

ГОСАЛ ЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИ ТАРСТАН

УДОСТОВЕРЕНИЕ
К
МЕДАЛИ

«ЗА ОТЛИЧИЕ В ТРУДЕ»

Таныклык бланкының эчке ягы үрнәге

| | |
|---|---|
| | Удостоверение<br>________________________________<br>фамилия<br>________________________________<br>имя<br>________________________________<br>отчество<br>________________________________<br><br>Приказом Госалкогольинспекции Республики Татарстан<br><br>от «_» ____20__г. №_____<br><br>награжден(а)<br>медалью<br><br>«ЗА ОТЛИЧИЕ В ТРУДЕ»<br><br>Руководитель Госалкогольинспекции Республики Татарстан<br>М.П. |

Татарстан

Республика
сы Дәүләт
алкоголь
инспекцияс
енең
19.04. 2018 ел,

№ 12-07/60
боерыгы
белән
расланды

**“Булышлык күрсәткән өчен” медале турында нигезләмә**

1. “Булышлык күрсәткән өчен” медале Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең ведомство бүләге булып тора.

2. “Булышлык күрсәткән өчен” медале белән гражданнар түбәндәге өлкәләрдә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә йөкләнгән бурычларны тормышка ашыруга нәтиҗәле төстә ярдәм иткән өчен бүләкләнә:

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшчәнлеге өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан үткәрелә торган чаралар кысаларында системалы бушлай юридик ярдәм күрсәтү һәм халыкны нәтиҗәле хокукый агарту;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм аның учреждениеләре хезмәткәрләренең ватанпәрвәрлек рухын үстерүгә, мәдәни һәм башка тәрбия, спорт һәм эстетик үсешенә ярдәм итү.

3. “Булышлык күрсәткән өчен” медале күкрәкнең сул ягына, башка бүләкләр янәшәсендә – сулгарак тагыла.

4. “Булышлык күрсәткән өчен” медаленең тасвирламасы һәм рәсемнәре бу Нигезләмәгә №1 кушымтада китерелгән. “Булышлык күрсәткән өчен” медаленең тасвирламасы һәм рәсемнәре бу Нигезләмәгә №1 кушымтада китерелгән. “Булышлык күрсәткән өчен” медаленә таныклык тасвирламасы һәм үрнәкләре бу Нигезләмәгә №2 кушымтада китерелгән.

“Булышлык
күрсәткән өчен”
медале турында
нигеләмәгә №1
кушымта

**“Булышлык күрсәткән өчен” медаленең тасвирламасы**

Медаль диаметры 40 мм лы түгәрәк рәвешендә ясалган.

Медальнең уң ягында уртага Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эмблемасы сурәтләнгән.

Эмблема “Госалкогольинспекция Республики Татарстан” дип язылган тасма белән каймаланган.

Медальнең кире ягында, түгәрәкнең югары өлешендә – «За содействие», түбәнге өлешендә – «Булышлык күрсәткән өчен» дигән сүзләр урнаштырылган. Медальдәге барлык сурәтләр һәм язулар да – рельефлы.

Медальнең уң һәм сул ягының тышкы контуры рантлар белән эшләнгән.

Медаль цинк эретмәсе белән корычтан эшләнеп, алтынсу төскә китерелгән һәм йомшак эмаль белән капланган.

Медаль колак һәм боҗра ярдәмендә яшел төстәге йомшак эмаль белән капланган, киңлеге 25,5 мм, биеклеге 19 мм га тигез булган дүрт почмаклы калыпка тоташтырылган.

Калыпның аскы өлешен калып уртасыннан уң һәм сул якка таба урнашкан башаклар үрелмәсе бизи.

Калып корычтан эшләнә, алтынсу төскә кертелеп, йомшак эмаль белән каплана.

Медальле калып эләктергеч ярдәмендә киемгә тагып куела.

Медальнең төсле макеты кушымта итеп бирелә.

“Булышлык
күрсәткән өчен”
медале турында
нигеләмәгә №2
кушымта

**«Булышлык күрсәткән өчен»**
**медаленең төсле рәсеме**



медале турында нигеләмәгә №3 кушымта

**«Булышлык күрсәткән өчен» медаленә таныклык бланкы тасвирламасы**

“Булышлык күрсәткән өчен” медаленә таныклык бланкы ак төстәге калын катыргыдан эшләнә. Ачып куйгач, таныклык бланкы үлчәме – 140х100 мм.

Таныклык бланкының беренче битенә (ябып куелган рәвештә) Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эмблемасының график сурәте урнаштырылган. Эмблема астына түбәндәге язулар урнаштырылган: ИКЕ юлга – «ГОСАЛКОГОЛЬИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН», ике юлга – «УДОСТОВЕРЕНИЕ К МЕДАЛИ» һәм бер юлга «ЗА СОДЕЙСТВИЕ» дигән сүзләр. Язулар кызыл буяу белән басылган.

Икенче битенең уртасына “Булышлык күрсәткән өчен” медаленең төсле сурәте урнаштырылган.

Өченче битнең югарыгы өлешендә – «УДОСТОВЕРЕНИЕ» дигән язу, язу астында – реквизитлар: фамилия, исеме, атасының исеме. Шуннан соң ике юлга – «Приказом Госалкогольинспекции Республики Татарстан» дигән сүзләр, түбәндәрәк бер юлга – «от» язуы һәм боерык реквизитлары: числосы, ае, елы һәм номеры урнаштырылган. Түбәндә бер юлга – «награжден(а) медалью» һәм тагын бер юлга – «ЗА СОДЕЙСТВИЕ» дигән сүзләр сыйдырылган. Шуннан соң ике юлда – «Руководитель Госалкогольинспекции Республики Татарстан» дигән сүзләр һәм мөһер урыны. «УДОСТОВЕРЕНИЕ» һәм «ЗА СОДЕЙСТВИЕ» дигән сүзләр кызыл буяу белән, калган бөтен текст – кара буяу белән басылган.

Таныклык бланкы үрнәге

ГОСАЛКО[illegible]ЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

УДОСТОВЕРЕНИЕ
К МЕДАЛИ

«ЗА СОДЕЙСТВИЕ»

Таныклык бланкының эчке ягы үрнәге

| | |
|---|---|
|  | Удостоверение<br>______________________________<br>фамилия<br>______________________________<br>имя<br>______________________________<br>отчество<br>______________________________<br><br>Приказом Госалкогольинспекции Республики Татарстан<br><br>от «_» ____20__г. №_____<br><br>награжден(а) медалью<br><br>«ЗА СОДЕЙСТВИЕ»<br><br>Руководитель Госалкогольинспекции Республики Татарстан<br>М.П. |

Татарста
н

Республика
сы Дәүләт
алкоголь
инспекцияс
енең
19.04. 2018 ел,

№ 12-07/60
боерыгы
белән
расланды

**Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Мактау грамотасы турында нигезләмә**

1. Мактау грамотасы Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең һәм «Татэкспертцентр» ГБУның ведомство бүләге булып тора.
2. Мактау грамотасы белән гомуми эш стажы кимендә 10 ел булган, били торган вазыйфасында – кимендә 3 еллык стаж туплаган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең һәм «Татэкспертцентр» ГБУның хезмәткәрләре бүләкләнә.

3. Мактау грамотасы белән бүләкләү турында үтенечнамә язуга нигез булып тора:

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең һәм «Татэкспертцентр» ГБУның бурычларын һәм программаларын тормышка ашыруда конкрет казанышларга ирешү;

производствода зур казанышларга ирешү һәм күп еллык намуслы хезмәт;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең һәм «Татэкспертцентр» ГБУның эшчәнлеген камилләштерүдә казанышларга ирешү;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә һәм аның учреждениеләрендә күп еллык нәтиҗәле хезмәт, күп еллык нәтиҗәле иҗтимагый эшчәнлек;

фәнни эшчәнлектә, физик культура һәм спортта, гражданнарны хокукый яктан тәрбияләү һәм агартуда, законлы мәнфәгатьләрен һәм хокукларын яклауда казанышларга ирешү.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Мактау грамотасы белән бүләкләнүгә тәкъдим ителә торган зат моңа кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән булырга тиеш.

5. Яңа казанышлар өчен Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Мактау грамотасы белән кабат бүләкләү алдагы бүләкләүдән соң кимендә 5 ел узгач хәл ителә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт алкоголь

инспекциясенең Мактау
грамотасы турында
нигезләмәгә №1
кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Мактау грамотасы бланкы тасвирламасы**

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Мактау грамотасы А3 форматындагы махсус кәгазьдә алтынсу төстәге шрифт ярдәмендә типографик ысул белән эшләнелә.

Кәгазьнең уң ягында Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эмблемасы сурәтләнгән, кәгазь уртасында ике юлда, кәгазь кырыеннан 15 мм ераклыкта, кызыл кысага «Госалкогольинспекция Республики Татарстан» дигән сүзләр урнаштырылган. Кәгазь уртасында ике юлда – «Почётная грамота», түбәндәрәк өч юлда – «Госалкогольинспекции Республики Татарстан Награждается» дигән сүзләр.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Мактау грамотасы тексты компьютер техникасы ярдәмендә басыла, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең имзасы мөһер белән раслана, аскы өлешенә бүләкләү турында Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы реквизитлары урнаштырыла.

Кәгазьнең кырыйлары алтынсу төстәге кыса белән әйләндереп алынган.

Татарстан
Республика
сы Дәүләт

алкоголь
инспекцияс
енең
19.04. 2018 ел,
№12-07/60 боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең Рәхмәте турында нигезләмә**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең Рәхмәте Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең һәм «Татэкспертцентр» ГБУның ведомство бүләге булып тора, кагыйдә буларак, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең һәм «Татэкспертцентр» ГБУның тәүге бүләгенә әйләнә.
2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең Рәхмәте били торган вазыйфасында эш стажы кимендә 1 ел булган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм «Татэкспертцентр» ГБУ хезмәткәрләренә белдерелә.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең Рәхмәте Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм «Татэкспертцентр» ГБУ алдындагы бурычларны хәл итүгә үзләреннән зур өлеш керткән башка затларга да белдерелергә мөмкин.
4. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең Рәхмәтен белдерү турында үтенечнамә язуга нигезләр булып тора:

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм «Татэкспертцентр» ГБУ алдындагы бурычларны хәл итүдә зур нәтиҗәләргә ирешү мөмкинлеге бирердәй производство, спорт һәм агарту эшчәнлегендә инициатива, активлык күрсәткән өчен;

производствода тотрыклы нәтиҗәләргә ирешкән өчен һәм күпьеллык намуслы хезмәт өчен;

югарыда телгә алып үтелгән уңышлар һәм казанышларга ия булганда, юбилей, әһәмиятле даталар уңаеннан.

5. Яңа казанышлар өчен Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең Рәхмәтен кабат белдерү элегрәк белдерелгәннән соң кимендә бер ел узгач хәл ителә.

Татарстан
Республикасы Дәүләт
алкоголь инспекциясе
җитәкчесенең Рәхмәте

турында Нигезләмәгә
№1 кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең Рәхмәте тасвирламасы**

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең Рәхмәте А4 форматындагы кзгазьдә алтынсу төстәге шрифт ярдәмендә типографик ысул белән эшләнелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе Рәхмәт кәгазенең уң ягында Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең бинасы схема рәвешендә сурәтләнгән, битнең уртасында югарыгы почмагыннан 80 мм ераклыкта ике юлга урнаштырылган «Благодарность руководителя Госалкогольинспекции Республики Татарстан» дигән сүзләр өстән һәм астан бизәк белән әйләндереп алынган. Кәгазьнең югарыгы сул почмагында – Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эмблемасы. Уртада, «Благодарность руководителя Госалкогольинспекции Республики Татарстан» дигән сүзләрдән соң түбәндәрәк югары почмагыннан 80 мм ераклыкта ике юлга «Госалкогольинспекция Республики Татарстан объявляет БЛАГОДАРНОСТЬ» дигән сүзләр урнаштырыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенең имзасы герблы мөһер белән раслана, аскы өлешенә бүләкләү турында боерык реквизитлары куела.

Кәгазьнең кырыйлары алтынсу төстәге кыса белән әйләндереп алынган.